Олы Әтнә урта мәктәбе

**Төбәкара үткәрелгән семинарның дәрес планы.**

# Тема. “Барыбызга да таныш Шүрәле”

**(Г.Тукайның “Шүрәле” поэмасы буенча 5 нче сыйныф)**

Үткәрде югары категорияле
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Сабирҗанова Светлана Илдус кызы

**Әтнә – 2015 нче ел**

**Тема. Барыбызга да таныш Шүрәле.** ( Г.Тукайның “Шүрәле” поэмасы буенча)

**Максат.** 1. “Шүрәле” әкиятенең үзенчәлекләрен аңлату.

2. Халык әкиятләреннән аермалы буларак, шигырь белән язылган булуы.

3. Татар сәнгатенең башка төрләренә дә этәргеч биргән әсәр булуын җиткерү.

4. Г.Тукай иҗатын өйрәнүгә кызыксыну уяту.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

**Метапредмет** – рәссам Б.Әлменов картинасы белән танышу.

**Регулятив универсаль уку гамәлләре:**

- Укытучының күрсәтмәләрен аңлап үти белү; анализлый белү; уку эшчәнлеген оештыра белү;уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен контрольгә ала **белү.**

**Танып- белү универсаль уку гамәлләре:**

- Уку максатын мөстәкыйль билгеләү; тиешле мәгълүматны табу, билгеләү; сөйләм берәмлекләрен логик эзлелеккә салу; объектларны чагыштыру, чагыштырып нәтибә ясый белү күнекмәләрен формалаштыру.

**Коммуникатив универсаль уку гамәлләре:**

-фикерне төгәл итеп җиткерү; әңгәмәдәшең белән аралашу калыбын төзү; мәгълүматны туплау өчен күмәк эш башкару.

**Шәхескә кагылышлы**: экологик тәрбия бирү.

**Материал:** 5 нче сыйныф әдәбият дәреслеге.

**Җиһазлау**: Экран, презентация, Б.Әлменовның “Шүрәле” картинасыннан репродукция, Г.Тукай “Шүрәле” китаплары.

**Кулланылган структура**: КОНЭРС, СТЁ ЗЕ КЛАСС

**Дәрес барышы.**

**I.Психологик-уңай халәт тудыру.**

**Укытучы.** Хәерле көн, укучылар! Барыбыз өчен дә бүгенге көн хәерле булсын, шатлык-куанычлар гына алып килсен. Күңелләребездә иман нуры балкысын. Шундый яхшы теләкләр белән әдәбият дәресен башлыйбыз.

Бүген безнең дәресебез гадәти түгел, чөнки бездә кунаклар бар, шуның өчен дәресебезне дә үзенчәлекле итеп башлыйк әле. Укучылар, рәхим итегез.

3 укучы такта янына чыга, 3 телдә "Шүрәле" поэмасыннан өзек сөйлиләр.

**Укытучы**. Укучылар, нинди әсәрдән өзекләр яңгырады?

**Укучы.** Г.Тукайның "Шүрәле" поэмасыннан инглиз, рус һәм татар телләрендә өзек яңгырады.

**Укытучы.** Ни өчен 3 телдә?

**Укучы.** Татар теле- безнең туган телебез, рус теле- икенче дәүләт телебез, ә инглиз теле  дөньяда аралашу өчен кирәк тел тел. Без бит мәктәптә дә 3 телне өйрәнәбез.

**Укытучы.** Укучылар, ә безнең татар телебез башка телләр арасында нинди урында тора соң?

Галимнәр планетабызның теләсә кайсы кешесе белән аралашу өчен 14 телне белү җитә дип саныйлар. Болар гарәп, инглиз, рус, япон, кытай һ.б. Шулар арасында безнең туган телебез татар теле дә бар. Ә беләсезме, Г.Тукай язган "Шүрәле" поэмасын да 15 телгә тәрҗемә иткәннәр.

**(Китап күрсәтелә)**

Укытучы. Әйе, укучылар безнең татар телебез шундый бөек, затлы тел икән.

Без бүген дәрестә нинди әсәр турында сөйләшүне дәвам итәбез ?

**Укучы.** Г. Тукайның "Шүрәле" поэмасы турында.

**Укытучы.**Әйе, укучылар, дөрес. Без үткән дәрестә поэманы укып таныштык. Тик әле Шүрәле поэмасы турында безгә белемнәребезне тагын да баетырга кирәк. Мин дәресебезнең темасын **"Барыбызга да таныш Шүрәле"** дип алдым. Минем белән килешәсезме , укучылар.( **слайдта тема һәм Шүрәле рәсеме күрсәтелә)**

Сезгә өйдә “Шүрәле” әкиятен укып килергә иде. Эчтәлеген сөйләп китик әле.

(Бер укучы әкиятнең эчтәлеген сөйли)

**Укытучы.** Ул ни өчен әкият дип атала?

**Укучы.** Әкият-табигать, тереклек, кешеләр катнашындагы маҗараларны хыял ярдәмендә мавыктыргыч итеп тасвирлаучы жанр.

**Укытучы.** Ә безнең дәреслектәге “Шүрәле” нинди жанрга карый?

**Укучы.** Г.Тукайның “Шүрәле” әсәре поэма жанрына карый, чөнки ул шигырь формасында язылган.

**Укытучы.** Нәрсә ул поэма? Дәреслектән укып китик әле.

**Укучы.** Поэма әдәбиятның эпик һәм лирик төр сыйфатларын алган үзенчәлекле жанр: сюжетында вакыйгалар белән хис-кичерешләр үрелеп тасвирлана.

**Укытучы.** Әйдәгез, халык әкияте белән Тукай әсәрен чагыштырып карыйк әле?

**Укучы.** “Шүрәле” поэмасы Кырлай авылы табигатен тасвирлау белән башланып китә, ә халык әкиятендә Кырлай авылы турында бер сүз дә юк.

**Укытучы.** Укучылар Г.Тукайның “Шүрәле” поэмасы сюжетына нигезләнеп төшерелгән мультфильмнан өзек карап китик әле. **(Слайд)**

Нәрсә күрдек? Поэма белән мультфильм арасында охшашлык бармы?

**Укучы.** Кырлай авылы табигатен, аның матурлыгын күрдек.

**Укытучы.** Укучылар поэманың беренче бүлегеннән сурәтләү чараларын табыйк әле?

(чагыштыру- зур бу урман: читләре күренмидер, диңгез кеби, бик хозур рәт-рәт тора гаскәр кеби чыршы, нарат)

(Эпитет Ак, кызыл, ал, сап-сары, зәңгәр, яшелдән чәчкәләр )

**Укытучы.** Поэмадагы һәм әкияттәге образларга игътибар итик әле?

**Укучы.** Поэмада да, әкияттә дә Былтыр образы бирелгән.

**Укытучы.** Егеткә нинди сыйфатлар хас?**Стё Зе Класс**

**(Әдәбият дәфтәрләрен ачып Былтыр образы дип язабыз. Сезгә бирелгән вакыт эчендә Былтырга хас сыйфатларны 1,2 дип баганалап язып төшәбез.**

**Хәзер соңгы язылган сыйфатның астына сызып куябыз. Дәфтәр белән ручканы алабыз. Урыннардан торабыз, урындыкларны этеп куябыз. Үзегезгә пар табасыз һәм җавапларны тулыландырасыз. Тагын пар табуны дәвам итәсез.**

**Вакыт бетте, урыннарга утырабыз. Кем ничә сыйфат язды? Иң күп язган кеше такта янына чыгып укый, үзегездә булган җавапларга тамга салып барасыз.)**

**Укучы**. Егет-батыр, эшчән, зирәк, тапкыр, хәйләкәр, шаян, куркусыз.

**Укытучы**. Егетнең шаянлыгы кайда күренә?

**Укучы**. Утынчының Шүрәле соравына "Исемем Былтыр булыр" дип җавап бирүендә.

**Укытучы**. Укучылар, поэмадагы батыр, тапкыр егетне Тукай уйлап тапты микән?

**Укучы**. Юк, ул герой татар әкиятләренә хас. Аны борынгы бабайлар уйлап тапканнар. Татар әкиятләренә карасак, татар егете тырыш, зирәк, уңган. Ә менә рус әкиятендәге Иван дурак эшләмичә мич башында ял итеп кенә ята.

**Укытучы**. Ә хәзер Шүрәле образына килик. Шүрәле поэмада ничек сурәтләнгән?( Дәреслектән Шүрәлене сурәтләгән урыннарны уку.)

**Экранда "Шүрәле"**

Шүрәлене уңай образга кертәбезме, тискәреме? Кемнәр уңай ди, кемнәр тискәре. Кул күтәрәбез.**КОНЭРС**

Уңай: шаян, күндәм, ярдәмчел, ышанучан.

Тискәре: куркыныч, кытыклап кешеләрне үтерү, тавышы ямьсез.

**Укытучы**. Укучылар, сезгә эзләнү эше бирелгән иде. Шүрәле тагын нинди әсәрләрдә телгә алына?

**Укучы.** А.С.Пушкинның "Руслан и Людмила" поэмасында елларда язылган Су анасы һәм Шүрәле искә алына. Там чудеса, там леший бродить, Русалка на ветвях сидит. Г.Тукай кечкенәдән рус язучысы Пушкин иҗатына гашыйк булган. Димәк, үзенең Су анасы һәм Шүрәле образарын да Пушкиннан алган дип уйлыйм мин.

**Укучы.** Мин "Риваятьләр һәм легендалар " китабында "Шүрәле" дигән легенда укыдым. Бу легендада Шүрәле шулай ук урманда яши. Ул урманга килүчеләрне адаштыра, юлдан яздыра.

**Укучы.** “Тутый кош” дигән татар халык әкиятләре җыентыгында “Таз белән Шүрәле” әкияте бирелгән. Таз урманга утынга барган. Шүрәлегә алдалап утын кистергән.

**Укучы.** Марсель Галиевнең “Шүрәле гаеплеме?” дигән китабында Шүрәле һәм җил турында шигырь бирелгән. Шүрәле җилне үз янына чакырып кытыкламакчы булган, тик җил Шүрәлене бөтереп алган һәм Шүрәле үзе көлкегә калган.

**Укытучы**. Күзәтүләрдән чыгып, нинди нәтиҗә ясыйбыз?

**Укучы**. Димәк, Шүрәле ул һәрвакытта урманда яшәгән.

**Укытучы**. Әйе, укучылар Шүрәле ул-урман хуҗасы. Безнең борынгы бабаларыбыз табигать белән тыгыз бәйләнештә яшәгәннәр, аларны табигать ашаткан һәм киендергән. Яшәү чыганагы булган суны, үз сыйлары белән туендырып торган урманны алар кадерләгәннәр.Шүрәле урманга хуҗа булса, явыз адәмнәр зыян сала алмас дип уйлаганнар.

**Укытучы.** Укучылар, Г.Тукай үзе Шүрәлегә ышанганмы? Әйдәгез, Г.Тукайның “Сабыйга” шигырен искә төшерик әле.

(Бер укучы сәнгатьле укый)

**Укучы**. “Сабыйга” шигыре Тукайның “Шүрәле” әсәренә дәвам кебек яңгырый. Уку, аң-белем генә безгә акны-карадан аерырга ярдәм итәчәк. Төрле явыз җаннарның барлыгына ышанмаса да, Тукай үзе дә Шүрәлене ярата кебек.Шүрәле тиз алданучан, беркатлы. Ул көлке чыганагы да, чөнки кытыклап, кешеләрне көлдерә. Тукай күп кенә әсәрләрен Шүрәле имзасы белән бастыра.

**Укытучы**. Әсәрдә нинди вакыйгалар күзәтелде?

**Укучы**.1. Кырлай авылы һәм урманы.

2. Былтыр һәм Шүрәле.

**Укытучы**. Укучылар, поэманың 1 бүлегенең соңгы юлларына игътибар итик әле: Ачыла алдында тарихтан театр пәрдәсе

Аһ! дисең, без ник болай соң? Без дә Хакның бәндәсе.

**Сүзлек эше Хакның бәндәсе – Алла, Хак-тәгалә кешесе**

Бу юлларда татар халкының данлы тарихына ишарә ителә. Тарих фәнендә монгол яулап алулары, рус патшаларының Себерне, Ерак Көнчыгышны буйсындырулары мәгълүм. Көнчыгыштан килгән Чыңгыз Хан күпсанлы гаскәре белән байтак илләрне, шулай ук безнең борынгы бабаларыбыз яшәгән Болгар дәүләтен дә буйсындыра. Г.Тукай поэмада шул

тарихи күренешне искә ала. Ә соңгы юлларда Явыз Иван тарафыннан яулап алынган халкыбызның хокуксызлыгына ишарә ителә.

Укучылар, безнең дәреслектә “Шүрәле” поэмасына иллюстрация бирелгән. Карап китик әле. Димәк, поэма тәэсирендә сәнгатьнең башка төрләре дә туган.

“Шүрәле” поэмасы бүген дә татар әдәбиятының таҗы булып санала. Бу әсәр – татар сәнгатенең башка төрләренә дә этәргеч биргән әсәр. Ф.Яруллинның “Шүрәле” балеты – музыка сәнгатенең классик үрнәге.Аңа Тукай поэмасы нигез ташы икәне бәхәссез.

“Шүрәле” поэмасы – рәссамнарның да иҗат фантазиясен уяткан әсәр. Б.Әлменов ясаган Шүрәле рәсемнәре Тукай хыялына бик туры килә. Сүз сәнгате белән рәсем сәнгатенең үзенчәлекләрен ачыклауда поэмада сурәтләнгән Шүрәле белән рәссам ясаган Шүрәле рәсеме – бик тә кулай, матур үрнәкләр. Шүрәленең портретында ук сәнгатьнең ике төре күзалдыбызга килә.

Бу әсәргә скульптор Б.Урманче да битараф калмаган, аның сәнгать әсәрләре арасында Шүрәле сыны да бар.

Ә менә математика укытучысы Айнур Илһамовичның әтисе Тукайга ияреп “Кырлай маҗаралары” поэмасын язган.

Укучылар, Г.Тукайның “Шүрәле” әсәре кайсы ягы белән әһәмиятле? Ни өчен без аны шулай яратып өйрәнәбез?

**Укучы.** Кырлай авылы үзенең урманы белән генә түгел, ә Былтыр кебек кыю, тапкыр уллары белән дә дан тота икән. Әсәрдә урманның матурлыгы егетнең тапкырлыгы белән кушыла. Димәк, авыл-урманы белән, кеше акылы белән гүзәл дип әйтә алабыз.Г.Тукай, кешенең көчле, сәләтле, батыр икәнен әйтеп, бернинди кара көчләрнең дә кешегә каршы тора алмавы турында сурәтли.

**Рефлексия.** Укучылар, дәрестә нинди яңалык белдегез?

**Үзбәя.** Укучылар, дәрестә барыгыз да актив катнаштыгыз, һәркем үзенә билге куя.

**Өй эше.** Иҗади эш. Дәрестә кичергән хисләргә таянып, Шүрәле турында хикәя, әкият яки шигырь язарга.